РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

14.01.2026 №18-п

Саба муниципаль районында махсус хәрби операция үткәрү зонасыннан кайткан МХО дә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын эшкә урнаштыру буенча эшче төркем төзү турында

1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында»,
2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» ,
1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы «Оборона турында»
Федераль законнарга таянып, махсус хәрби операция үткәрү зонасыннан кайткан МХО дә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча ярдәм күрсәтү максатларында, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районында махсус хәрби операциядән кайткан МХО дә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча эшче төркем булдыру.
2. Кушымтаны расларга
- Саба муниципаль районында махсус хәрби операция үткәрү зонасыннан кайткан МХО дә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча эшче төркем составы;
— Саба муниципаль районында махсус хәрби операция үткәрү зонасыннан кайткан МХО дә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча эшче төркем эшчәнлеге турында нигезләмә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат
4. -телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://saby.tatarstan.ru/, һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары – Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты Җитәкчесе И.Р. Гариповка йөкләргә.

Җитәкче М.Р.Кәримов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 ел, №______ карары белән РАСЛАНДЫ

Саба муниципаль районында махсус хәрби операция уздыру зонасыннан кайткан МХО дә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча эшче төркем составы.

| | |
|---|---|
| Гарипов И.Р. | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты Җитәкчесе, рәис |
| Хәбибуллин И.Г. | Саба районы буенча "Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ бүлеге башлыгы (килешү буенча), рәис урынбасары |
| Баһманов М. М. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары - икътисад бүлеге башлыгы, рәис урынбасары |
| Миннеханов Л.М. | Саба районы буенча "Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ бүлегенең әйдәп баручы инспекторы (килешү буенча), сәркатип |
| Эшче төркем әгъзалары: | |
| Йосыпов М.Р. | Саба район үзәк хастаханәсе" ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Заһидуллин Р.Ф. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Гайнетдинова Л. Н. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Саба муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мәүлетова А.М. | Татарстан Республикасы буенча "Ватанны саклаучылар" махсус хәрби операциясендә катнашучыларны дәүләт ярдәм фонды филиалының Саба муниципаль районында социаль координаторы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шакиров И.Ф. | «Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Закиров Ф.Ф. | Саба һәм Теләче районнары буенча хәрби комиссар (килешү буенча) |
| Гатауллин Ф.К. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сәлимов И. | Россия Федерациясе УФСИНның Татарстан Республикасы буенча УИИ Арча межмуниципаль филиалының өлкән инспекторы, эчке хезмәт капитаны (килешү буенча) |
| Авыл (шәһәр) җирлекләре башлыклары | Килешү буенча |

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән
___________ 2025 ел, №___

Нигезләмә
махсус хәрби операция зонасыннан кайткан МХО дә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча эшче төркемнең Саба муниципаль районындагы эшчәнлеге турында

1. Саба муниципаль районында махсус хәрби операция зонасыннан кайткан МХО дә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча эшче төркемнең эшчәнлеге турында әлеге Нигезләмә (алга таба — Нигезләмә) МХО дә катнашучыларны эшкә урнаштыру буенча эшче төркемнең эш тәртибен билгели (алга таба — эшче төркем).

1.1. Эшче төркем 2023 нче елның 12 декабрендәге №565-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында" Федераль законны гамәлгә ашыру максатында булдырылган.

1.2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Эшче төркем үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр, милек рәвешләренә карамастан, вазыйфаи затлар белән берлектә алып бара.

1.4. Эшче төркем карарлары тәкъдим итү характерына ия.

2. Эшче төркемнең бурычлары һәм функцияләре.

2.1. Эшче төркемнең төп бурычлары булып:

- индивидуаль планнар эшләү, резюме төзүдә, вакансияләр сайлауда, укыту һәм квалификация күтәрү программаларында ярдәм итү, әңгәмәгә һәм киләчәктә эшкә урнашу өчен әзерлек;

- МХО зонасыннан кайтканнарны эшкә урнаштыру һәм һөнәри укыту чараларын гамәлгә ашыру һәм гражданнарның мәшгульлеген саклап калуга һәм үстерүгә, эшкә урнашу өчен эш урыннары булдыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында кызыксынган яклар эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

- эшче төркем эшчәнлеге белән бәйле башка бурычларны үтәү тора.

2.2 Эшче төркем эш бирүчеләрдән һәм башка органнардан Эшче төркем компетенциясенә кергән мәгълүматны соратырга һәм алырга хокуклы.

2.3. Эшче төркем утырышына җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, эш бирүчеләр вәкилләре чакырылырга мөмкин.

2.4. Эшче төркем утырышын алып бару аның рәисе тарафыннан башкарыла, ә аның булмавы очрагында — эшче төркем рәисе урынбасары яки эшче төркем рәисе йөкләмәсе буенча аның әгъзаларының берсе тарафыннан.

2.5. Эшче төркем утырышын әзерләү, аның әгъзаларын һәм чакырылган затларны хәбәр итү эшче төркем сәркатибенә йөкләнә, ә аның булмау очрагында рәис йөкләмәсе буенча әгъзаларның берсенә йөкләнә.

2.6. Эшче төркем утырышлары кергән гаризаларны карау кирәклегенә карап үткәрелә. Эшче төркем утырышы, әгәр анда эшче төркем әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

2.7. Эшче төркем карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы эшче төркем әгъзаларының күпчелеге тарафыннан кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, эшче төркем рәисенең тавышы хәлиткеч була.

3.Эшче төркем карары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Ул эшче төркем утырышында рәислек итүче тарафыннан имзалана.

3.1. Эшче төркем компетенциясе кысаларында кабул ителгән карарлар эшче төркем әгъзаларына, шулай ук эш бирүчеләргә, эшче төркем утырышларында каралган һәм (яки) тыңланган затларга җибәрелә.

3.2. Эшче төркем утырышында кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тоту шул утырышта рәислек итүчегә йөкләнә.

3.3. Эшче төркем утырышы беркетмәсен алып бару һәм җибәрү эшче төркем җаваплы сәркатибе тарафыннан башкарыла.